**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.11.2024 № 1430

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү хакы нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2020 елның 21 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пункты белән расланган норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 21 ноябрендәге 1430 номерлы карарына кушымта

РАСЛЫЙМ
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе
__________________Ә.К. Габдуллин

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү хакы нормативы

| Норматив исеме | Уку чорында бер укучыга көнгә бәя нормативы, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү хакы нормативы | 9,6 | 10,0 | 10,4 |